**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ 15.12. 2021

КАРАР № 92

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа шашы авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы уставы нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа шашы авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 октябрендәге 10-53/13526 номерлы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа шашы авыл җирлеге генераль планын, электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.
2. Әтнә муниципаль районы Яңа шашы авыл җирлеге советына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа шашы авыл җирлегенең генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru).
3. Әтнә муниципаль районы Яңа шашы авыл җирлеге советына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа шашы авыл җирлегенең 2012 елның 26 декабрендәге 57 номерлы Генераль планын раслау турында элегрәк кабул ителгән карарны үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов